ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

Җир кишәрлекләрен беренче чиратта инвалидлар һәм составында инвалидлар булган гаиләләр алу тәртибен һәм шартларын законнар белән җайга салу мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Җир кишәрлекләрен беренче чиратта инвалидлар һәм составында инвалидлар булган гаиләләр алу тәртибен һәм шартларын законнар белән җайга салу мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгатен кабул итәргә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе В.В. Володинга җибәрергә.

3. Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының күрсәтелгән Мөрәҗәгатен хуплауны үтенеп мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2020 елның 26 ноябре
№ 720-VI ДС